КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 декабрь г.Казань № 1314

Татарстан Республикасының цифрлы трансформация программасын раслау турында

Цифрлы нигездә үстерү, тормыш сыйфатын һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару шартларын яхшырту өчен мәгълүмат технологияләрен файдалану буенча хөкүмәт комиссиясе президиумы утырышы беркетмәсе нигезендә, Икътисад, социаль өлкә һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендәге стратегияне тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының цифрлы трансформация программасын расларга.
2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына бу карар белән расланган Татарстан Республикасының цифрлы трансформация программасына таянып эш итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, теләсә нинди оештыру-хокук рәвешендәге оешмаларга – аңа таянып эш итүне тәкъдим итәргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин